| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2021 Казан шәһәре № 1-1/т-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.10.2020 № 106-3/т-2020 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Тарифлар, 2021 елның җайга салу чорыннан тыш, бер елдан да ким булмаган вакытка билгеләнә.»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Тарифлар ел саен 1 гыйнвардан башлап (2022 елның җайга салу чорына һәм алдагы елларга) яртыеллыкларга календарь буенча бүлеп, әлеге тарифларның чираттагы җайга салуның бер еллык чорында беренче ярттыеллыкта 31 декабрьгә карата алдагы җайга салуның бер еллык чорындагы икенче яртыеллыгында тиешле тарифлар күләмен арттырмавына карап билгеләнә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев